## Кемгә, кая бирелә?

Фитыр садакасы башка зәкят маллары хисабына кереп, мохтаҗрак кешеләргә бирелә. Күп кешеләр мәчеткә бирә, мәчет файдасына дип. Бу дөрес түгел. Биргән садакагыз фитыр садакасы булмый, кире бирү тиеш була. Чөнки Раббыбыз безнең бер-беребезне шатландыру, бәйрәм хасил булсын өчен һәм уразабыздагы булган кимчелекләрне камилләштерү өчен, фитыр садакасын фарыз иткән. Уйлап карасак бит, нигә фитыр садакасы микъдарында кешене ашату куелган? Раббыбызның биргән ризыкларны, садакаларны кеше гаиләсенә алып кереп, урамда, мәчетләрдә генә бәйрәм булмасын, һәрбер өйнең эчендә дә бәйрәм булсын диюе түгелме?

Садаканы зәкят фарыз булмаган кешегә бирсәң дә була. Ягъни кемнең нисабы тулып, тиешле малларына бер ел үткән, бу кешегә зәкят фарыз була, ә калганнарга фарыз түгел. Димәк, аларга бирү дөрес.

## Ничек бирергә?

Фитыр садакасын бертуганыңа, якыннарыңа бүләк дип бирсәң дә була. Чөнки садака дисәң, кеше кыенсынырга мөмкин. Әгәр 2 - 3 кг печенье, конфет алып керсәң, бу бер кешенең фитыр садакасы күләме була. Шулай ук фитыр садакасын яшереп бирергә мөмкин. Мәсәлән, капкага, ишеккә, эт-песи тия алмаслык җиргә элеп китсәң һ.б. Моның хикмәте, беренчедән, яшереп биргән садаканың әҗер-савабы зур. Икенчедән, берәрсе әйберен урласа, бөтен кешедән шикләнгән кебек, әгәр аңа садака биргәннәр икән, ул бөтен кешене дә аңа биргәндер, дип уйлый. Бу кешеләрнең арасын якынайта.

## Хикмәтләре

Беренчедән, ураза тотучы кешенең ураза тоткандагы кимчелекләрен бетерә. Икенчедән, бәйрәм хасил була, үзенең кырындагы кешеләргә игътибары арта. Бер генә тапкыр булса да сорау туа: «Кемгә бирим? Кем мохтаҗрак? Кемнең өстендә минем хакым күбрәк?» Өченчедән, гаделлек, тигезлек хасил була. Чөнки бер кеше үзе фитыр садакасы бирсә, аңа кире үзенә шул ук вакытта унны бирергә мөмкиннәр. Фитыр садакасын бер-беребезгә бирешәбез. Әгәр беребез кемгәдер садакасын бирсә, аңа үзенә бирелергә тиеш түгел, дигән сүз дөрес түгел. Кемдер бер өлеш садака бирә, 2-3 өлеш ала. Кемдер бер яки күпмедер өлеш бирә.

## Кайчан бирергә?

Фитыр садакасын ураза бәйрәменә кадәр бирергә кирәк. Намазга барганда өенә калдырып китсәң, иң яхшы, гүзәл вакыт. Тагын да кабатлап әйтәбез: фитыр садакасы, зәкят кебек, кешеләргә бирелә, мәчет файдасына, керем-чыгымнарына бирелми. Мәчеткә башка садака рәвешендә бирелә.

## Кемнәргә бирсәң ярый?

Бертуганыңа, ике туганыңа, дин кешесенә.

## Кемнәргә бирелми?

Улына, кызына, оныгына, әтисенә, бабасына, әнисенә, әбисенә, хатынына.

Чөнки аларга ир кеше болай гына бирергә тиеш, аның бурычы. Ә хатыны иренә бирергә мөмкин (байлыгы булса), чөнки ирне ашату хатынның бурычы түгел.

**(“Татар мөселман календаре”ннан)**

---

***УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ***

# *Изге Рамазан ае*

Бар галәмне нурга күмеп,
Изге Рамазан башлана.
Коръән иңдерелгән бу ай
Иң мөбарәк айлардан санала.

Бу изге ай – сабырлык ае,
Аның әҗере – җәннәт.
Рәхмәт, гафу, мәгъфирәт көннәре –
Уттан котылуга сәбәп.

Җәннәт ишеге ачык булып,
Тәмугка юл бикләнер.
Бу айда ураза тотучының
Барлык теләкләре үтәлер.

Сәхәр ашап, ифтар кылганда
Күңелләрдә иман яңара.
Кешенең игелеге өстен булыр
Кыяматтә Раббыбыз каршында.

Хәләлне хәрәмнән аермый
Өстегезгә гөнаһ җыймагыз!
Ходайның әҗерен өмет итеп,
Ризыктан нәфесегезне тыегыз.

Мөселманны сынарга бирелгән
Рамазан ае – мөбарәк!
Тәннәр сихәтләнеп, рәхәтлек
алырбыз
Намаз укысак бергәләп.

Гөнаһларны гафу кыл, Ходаем,
Шатлыкта үткәрик бу айны.
Рамазан-Шәрифкә багышлыйм
Хисләрдән тупланган уйларны.

**Саимә МОРЗАХАНОВА.**
Гали авылы,
Похвистнево районы.





## Шәфкать һәм мәрхәмәт ае

Ураза кешеләрдә шәфкать һәм мәрхәмәт тойгыларын да уята. Ач һәм сусыз торып, ярлыларның хәлен аңларга, аларга ярдәм итәргә өйрәтә. Ә бит уйлап карасаң, бүгенге заманда да бу дөньяның төрле почмакларында бер телем икмәккә тилмереп, ачка үлүчеләр дә бар. Хәер, безнең илдә дә хәзер бизмәннең байлардан бигрәк ярлылар, мохтаҗлык кичерүчеләр ягы авырая бара түгелме? Ә үз гомерендә ач һәм сусыз торуның нәрсә икәнен белмәгән кеше аларның хәлен аңлармы соң? «Ачның хәлен тук белмәс», – дип тикмәгә генә әйтелмәгән. Шуңа күрә дә исламда иң күп ярдәмләшү ае Рамазан ае санала. Мөселманнар бу айда зәкят һәм садакаларын биреп, ярлыларны шатландыралар. Бу айда, гомумән, җәмәгать арасында да якынлык һәм самимият арта.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү галәйһи вә сәллам әйтә: “*Ураза тоту — ул олуг гыйбадәт. Әгәр адәм баласы Аллаһы кушканны үтәп, тыйганыннан тыелса, аның әҗер-савабы бу дөньялыкта ук гамәлгә ашачак”.* Әйе, Рамазанда булган хикмәтләрнең берсе адәм баласының кыямәт көненә әзерләнүенә кагыла. Бу айда кылган һәрбер изгелек өчен Аллаһы Тәгалә әҗер-савапларын меңләгән мәртәбәләр арттырып бирермен дигән. Кодси хәдисләребезнең берсендә Аллаһыбыз әйткән сүзләр китерелә: *“Яхшы гамәлләре өчен кешеләр һәр очракта да бүләкләнә. Әмма ураза Минем хакка гына тотыла һәм Мин һәркемгә дә тиешле әҗерен бирәмен”.* Шуңа күрә дә кешеләр бу айда күбрәк изге гамәлләр кылырга, сабыр булырга омтыла. Рамазан ае — үз-үзеңне, гамәлләреңне, уй-фикерләреңне, ниятләреңне контрольдә тоту, ягъни 30 көнлек сабырлыкка күнекмә (тренинг). Алай гына да түгел, Рамазан ае адәм баласына гөнаһларыннан, кимчелекләреннән арыну, нәфесен тезгенләү, холык-фигылен үзгәртү өчен дә бик яхшы форсат булып тора. Дөрес, шушы 30 көнеңне яхшы гамәлләрдә генә уздырып, ә ураза беткәч, кире көндәлек тәртипсезлеккә кайту адәм баласының рухи яктан көчсезлеген күрсәтә. Ә менә Рамазан аенда алган рухи көчне, ихласлыкны 11 ай буена саклап кала алу - көчле рухлыларга гына мөмкин эш. Шуңа да Аллаһы Тәгаләгә тәүбәгә килергә, яхшы гамәлләр генә сорарга кирәк.

Ураза нәрсә дигәнне аңлата? Ураза — гарәпчәдән “саум”, ягъни тыелу дигән сүзне аңлата. Бу очракта ашау-эчүдән генә түгел, ә якынлык кылудан, яман эшләрдән, гайбәттән дә тыелу.

Кемнәргә ураза тоту фарыз? Ураза тоту балигъ булган, сәламәт, акыллы һәрбер мөселманга фарыз гамәл. Аллаһының кодрәте киң, ул йөкле һәм бала имезүче хатыннарга, мосафирларга, сәламәтлекләренә зыян килүдән курыккан кешеләргә Рамазанда ураза тотмаска рөхсәт итә.

**Уразага ният ничек кылырга?** Рамазан уразасын иртә таңнан ният кылып башларга кирәк. Әмма кеше нинди ураза тотуын аңлатырга тиеш. Уразаның берничә төре бар, мәсәлән, нәфел, каффәрәт уразасы, каза уразасы, нәзер уразасы һәм башка бик күп уразаларыбыз да бар әле. Рамазан аенда бер генә уразаны тоту ваҗиб.

**Ураза кайчан бозылыр?** Әгәр дә ялгышып, уразасын ачса, я булмаса, көчләп ачтырсалар, яисә ахшам вакыты керде, дип уйлап, авыз ачса, эчемлек эчсә, авыздан, я булмаса, борын тишегеннән дару кабул итсә, косса. Әмма ихтыярсыз косу, онытып ашау уразаны ачмас, каза да ваҗиб булмас.

Ураза тота алмаганнарга нишләргә? Ураза тота алмаган, сәламәтлеге мөмкинлек бирмәгән кешегә уразасын ачса да, гаеп булмас. Соңыннан һәр көне өчен бер ятимгә, я булмаса, берәр мескенгә фитыр садакасы кадәр тәгам бирү урынлы. Әгәр дә соңыннан уразасын тотарга ниятләсә, тотасы уразасы казага калыр.

Уразаның файдасын санап бетерерлек түгел. Ул кешенең рухи дөньясын пакьләп кенә калмый, ә сәламәтлегенә дә уңай йогынты ясый әле. Мәсәлән, ашказанына, ашкайнату системасына даими эшләүдән ял бирә, организмнан төрле шлакларны чыгара һәм аны ныгыта.

Әйе, чыннан да, Рамазан-шәриф ае шәригать буенча хәерле ай дип саналса да, әгәр дә кеше аны тиешенчә үтәмәсә, аракы эчеп, сыра чөмереп, үзен тәртипсез тотып, тыйганнан тыелмыйча яши икән, әлбәттә, бу изге айның бернинди дә бәрәкәте булмый дигән сүз.

Быел уразаның беренче көне 20 июльгә, ягъни жомгага туры килде. 19 июль кичендә барлык мөселманнар беренче тәравих намазына җыелдылар. Көн озын булу сәбәпле, тәравих намазларын 8 рәкәгатькә кадәр дә кыскартырга мөмкин, әмма теләге булган кеше тулысынча 20 рәкәгать итеп тә укый ала.

## Ураза шартлары

Уразаның шартлары “вөҗүб” һәм “әда” дигән өлешләргә бүленә. Вөҗүб шартлары: мөселман булу, акыллы һәм балигъ булу. Кеше бу сыйфатларның берсеннән генә мәхрүм булса да, аңа ураза тору фарыз түгел. Әда шартлары: сау-сәламәт булу, өйдә тору, ният кылу һәм хәез-нифастан (күремнән) пакь булу. Шулай ук чирле һәм юлчы кешеләр өчен ураза тоту фарыз түгел. Алар авырган чакта яки сәяхәт вакытында калдырган уразаларын соңрак каза кылыр. Ният әда шартлары арасында бик әһәмиятле урын били. Ният итмичә тотылган ураза чын ураза булып саналмый.

## Уразаның вакыты

Уразаның вакыты — таң атудан (ягъни кояшның кызыллыгы сизелә башлаганнан) алып кояш баешына кадәр дәвам иткән мөддәт.

## Ураза ниятләре

Уразаның теләсә нинди төренә дә калеб белән ният итү җитәрлек санала. Ураза вакытында сәхәргә тору да бер ниятләр. Тел белән ният итү дә диндә яхшы дип санала. Рамазан уразасы билгеләнгән нәзер һәм нәфел уразасы өчен ният кылу вакыты